**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

02.10.2013 561-п

## Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 22 ноябрендәге 489-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 22 ноябрендәге 489-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.10 пунктының 2-4 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү – 6000 сум, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү – 600 сум, үзгәрешләр кертү (җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булу срогы озайтылган очракта) – 600 сум»;

2.12 пунктта «30 минут» сүзләрен «15 минут» сүзләренә алмаштырырга; 3.3.2 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне инициацияләүче гариза бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми»;

түбәндәге эчтәлекле 5.7 пункт өстәргә:

«5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә»;

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (В.А. Тронин):

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын, үзгәрешләре белән бергә, Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталында урнаштырырга.

3. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.М.Акчуринга йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров